**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
УРЮМСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЮМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 54-0-38, факс 54-0-38

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**21.09. 2020** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Урюм торак пунктында, гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Урюм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның октябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлегенең Урюм торак пунктында урнашкан Урюм авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрергә.

.

2. Гражданнар җыенында тәкъдим ителүче мәсьәләне расларга:

“Сез, 2020 елга җыелган 204325 (ике йөз дүрт мең өч йөз егерме биш) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Урюм авылының урамнарындагы юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу”дан “Урюм авылының Чапаев һәм Пушкин урамнарына вак таш һәм ком түшәү өчен ком сатып алу һәм техника яллау”га күчерергә ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Урюм авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Н.М. Краснов**